**СОВЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,42319

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы утырышы
КАРАРы

2019 елның 18 апреленнән № 48 -281

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2017 елның 30 октябрендәге 30-175 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

2007 елның 2 мартында чыккан «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 25-ФЗ номерлы Федераль закон, «Коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнары үтәлешен контрольдә тотуны камилләштерү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 3 августындагы 307-ФЗ номерлы Федераль законның 11 статьясы, «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең контроль – хисап органнары эшчәнлеген оештыруның гомуми принциплары турында"гы Федераль законның 7 статьясына һәм «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында «Федераль законның 13 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 27 декабрендәге 559-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2017 елның 30 октябрендәге 30-175 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында муниципаль хезмәт турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

- 9.5.1. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «9.5.1. шәхси яки ышанычлы затлар аша эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шөгыльләнергә, коммерция оешмасы яки коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашырга (сәяси партия белән идарә итүдә катнашудан тыш; түләүсез нигездә профсоюз органы, шул исәптән Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы җирле үзидарә органында оешкан беренчел профсоюз оешмасының сайлану органы, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы" муниципаль берәмлеге сайлау комиссиясе белән идарә итүдә катнашу»); башка иҗтимагый оешманың съездында (конференциясендә) яки торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары, күчемсез милекчеләр ширкәтләренең гомуми җыелышында катнашу; санап кителгән коммерцияле булмаган оешмалар белән түләүсез нигездә идарә итүдә катнашу (сәяси партиядән һәм профсоюз органы, шул исәптән Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы җирле үзидарә органында оешкан беренчел профсоюз оешмасының сайлану органыннан тыш), бердәнбер башкарма орган сыйфатында яисә аларның коллегиаль идарә органнары составына эшкә алучы вәкиленең (эш бирүченең) муниципаль хокукый акт белән билгеләнгән тәртиптә алынган рөхсәте белән керү, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә

идарә органнарында һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы' муниципаль берәмлеге гамәлгә куючы (акционер, катнашучы) булып торган оешманың ревизия комиссиясендә гамәлгә ашырудан кала, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы" муниципаль берәмлеге исеменнән муниципаль милектә булган акцияләр (устав капиталы өлешләрендә катнашу) белән идарә итү яки оештыру вәкаләтләрен гамәлгә ашыру тәртибен билгеләүче муниципаль хокукый актлар нигезендә; Федераль законнарда каралган башка очраклар»;

- 9.6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: « 9.6. Җитәкче булган муниципаль хезмәткәр, күрсәтелгән вазыйфаны биләү чорында, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы җирле үзидарә органында, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге сайлау комиссиясе аппаратында мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау максатларында, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының әлеге җирле үзидарә органының сайлау профсоюз органында, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге сайлау комиссиясе аппараты муниципаль хезмәткәрләренең мәнфәгатьләрен яклый алмый.»;

- 13- бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 13.8. пункт өстәргә: «13.8. Гражданин Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы Рәисе, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе, Татарстан Республикасы “Яңа Чишмә муниципаль районы” муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан суд һәм хокук саклау органнары җитәкчеләре белән якын туганлыкта (ата-аналары, хатыны балалары, бертуган абый яки сеңелләре, шулай ук тормыш иптәшенең бертуган абый яки сеңелләре, ата-аналары, балалары, балаларының тормыш иптәшләре) булган очракта «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Контроль-хисап органы рәисе вазыйфасына, ә муниципаль хезмәткәр контроль- хисап органы рәисе вазыйфасына билгеләнә алмый.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында» https://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырырга (халыкка игълан итәргә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы Аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә
муниципаль районы Башлыгы В.М. Козлов